КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 20 май г.Казань № 340

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мишә» төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать зоология (аучылык) тыюлыгы турында» 2004 ел, 29 гыйнвар, 41 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 24 март, 192 нче; 2011 ел, 13 май, 393 нче; 2014 ел, 17 октябрь, 767 нче; 2017 ел, 30 сентябрь, 737 нче; 2018 ел, 21 май, 382 нче; 2018 ел, 25 декабрь, 1223 нче; 2019 ел, 27 март, 226 нчы; 2021 ел, 20 декабрь, 1255 нче; 2022 ел, 22 февраль, 152 нче; 2022 ел, 28 февраль, 183 нче; 2023 ел, 13 ноябрь, 1472 нче, 2024 ел, 18 март, 155 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Мишә» төбәк әһәмиятендәге дәүләт табигать зоология (аучылык) тыюлыгы турындагы нигезләмәгә, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (карарга теркәлгән).

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 ел, 18 март, 155 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

14 пунктта «2 пунктның дүртенче абзацын,» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин